Банк России

# ФИШИНГТАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА

Фишинг – алдаучылыкның бер төре, охшатып ясалган сайтлар ярдәмендә кешенең шәхси мәгълүматларын, я акчасын урлау. Еш кына алдакчылар чын оешмалар сайтларына ике тамчы су кебек охшаган сайтлар ясыйлар.

## НИЧЕК ФИШИНГ САЙТЫНА ЭЛӘГЕРГӘ МӨМКИН?

Интернет яки электрон почта сылтамалары буенча, смс, мессенджерлар, социаль челтәрдәге хәбәрләр, рекламалар, лотереяләр турындагы белдерүләр, арзан бәядәге товарлар сату, дәүләт компенсацияләре буенча

! **Хакерлар еш кына чит кешеләрнең аккаунтларын ватып ачалар, һәм фишинг сылтамасы хәтта танышлардан да килергә мөмкин**

## ФИШИНГ САЙТЫН НИЧЕК ТАНЫРГА?

- **Адрес** чын адрестан тик бер-ике символ белән генә аерыла
- **Адрес юлында** https һәм ябык йозак билгесе юк
- **Дизайн** сыйфатсыз күчерелгән, текстларда хаталар бар
- **Сайтта** битләр аз, хәтта бер генә – картаның мәгълүматларын кертү өчен

## ФИШИНГТАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА?

- **Антивирус** куегыз һәм аны даими яңартып торыгыз
- **Кирәкле сайтларның** адресларын билгеле җирдә саклагыз
- **Шикле сылтамалар** буенча күчмәгез
- **Интернетта сатып алу өчен** аерым карта кулланыгыз, аңа кирәкле сумманы түләү алдыннан гына салыгыз

Кибергигиена кагыйдәләре турында тулырак **fincult.info** да укыгыз

**Финанс культурасы**